**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

«15» апрель, 2025 ел №5

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законнын 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексынын 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун ел вакытка расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 19 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (kukmor.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә түбәндәге адресларда урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

Түбән Өскебаш ав., Совет ур., 66а й. (Мәдинbackground йорты);
Югары Өскебаш ав., С.Ахтямов ур., 38А й. (клуб бинасы).
Битлянгур ав., Гагарина ур., 35 й(клуб бинасы)
Красная Гора ав., Дуслык ур., 64 й(клуб бинасы)

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: Н.М.Мөхәммәтҗанов

ОГРН 1021600752759
ИНН 1623002008

Татарстан Республикасы Кукмара районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советының 2025 елның 15 апрелендәге 5 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы**

**1 номерлы бермандатлы Мәктәп сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 96

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Югары Өскебаш авылы (С.Ахтямов урамының 1 – 63 йортлары).

**2 номерлы бермандатлы Клуб сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 92

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Югары Өскебаш авылы (С.Ахтямов урамының 65-99 нче, Мәктәп урамның 2-36 нчы, Киров урамының 2-6 йортлары, Битлянгур авылының Комсомольская урамының 26-47 нче йортлары).

**3 номерлы бермандатлы Гагарин сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 95

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Битлянгур авылы (Нух Идрисов урамының 6 нчы йорт, Гагарин урамының 2А-56 нчы йортлары).

**4 номерлы бермандатлы Комсомол сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 95

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Битлянгур авылы (Гагарин урамының 58-83 нче, Комсомол урамыны 1-25 йортлары )

**5 номерлы бермандатлы Түбән сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 112

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Түбән Өскебаш авылы (Совет урамының 1 - 66 нче, , Яшьләр урамының 1 - 8 нчы йортлары).

**6 номерлы бермандатлы Базар сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 112


Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә:Түбән Өскебаш авылы (Совет урамының 68-126 нчы йортлары).

**7 номерлы бермандатлы Урман сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 112

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Түбән Өскебаш авылы (Совет урамыың 128-168 нчы йортлары, Пилорама урамының 1-6 йортлары), Красная Гора авылы(Дуслык  урамы 3-62 йортлар)

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте**




| № округа | Наименование округа |
|---|---|
| 1 | Школьный |
| 2 | Клубный |
| 3 | Гагарина |
| 4 | Комсомольский |
| 5 | Нижний |
| 6 | Базарный |
| 7 | Лесной |